ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«ЛЕНИНОГОРСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН

«ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2026 елның «28» гыйнвары № 42

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының «2026-2030 елларга Лениногорск муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү» программасын раслау турында» 2025 елның 20 ноябрендәге 997 номерлы карары белән расланган «2026-2030 елларга Лениногорск муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү»программасына үзгәрешләр кертү хакында

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Советының «2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы бюджеты турында» 2025 елның 15 декабрендәге 39 номерлы карарын үтәү йөзеннән Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының «2026-2030 елларга Лениногорск муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү» программасын раслау турында» 2025 елның 20 ноябрендәге 997 номерлы карары белән расланган «2026-2030 елларга Лениногорск муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү»программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Программа паспортында:

«Программаны еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп финанслау күләме» бүлегенә түбәндәге редакциядә «2026 елга республика бюджеты исәбеннән» юл өстәргә:

югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен тренер-укытучыларга бүләкләү түләүгә, шулай ук спорт резервы әзерләүче Лениногорск муниципаль районының муниципаль физкультура спорт оешмаларында эшләүче спортчы-инструкторларга һәм спортчыларга ярышларда алган нәтиҗәләре өчен 1200 мең сум;

Лениногорск муниципаль районының спорт резервы әзерләүче физкультура спорт оешмаларының яшь белгечләренә акчалата түләүгә 20 мең сум.»

Программаның 3 нче кушымтасын кушымтада бирелгән яңа редакциядә расларга.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Г.Х. Вагыйзовага йөкләргә.

Җитәкче И.Г.Шәмәрданов

М.М.Хәсәнов
5-49-40

«2026-2030 елларга Лениногорск муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү» муниципаль программасына 3 нче кушымта

## «2026-2030 елларга Лениногорск муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү» муниципаль программасының максатлары, бурычлары  һәм программа чаралары буенча финанслау

| № т/б | Максатның исеме | Бурычның исеме | Чараның атамасы | Башкаручылар | Төп чараларны үтәү сроклары, еллар | Финанслау чыганагы | Финанслау, мең сумнарда |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | 2026 |
| 1. | Лениногорск муниципаль районында физик культура һәм спорт өлкәсендә дәүләт сәясәте программасын гамәлгә ашыру | Массакүләм физик культураны һәм спортны үстерү, халыкның сәламәтлеген ныгыту, Лениногорск районының спорт имиджын ныгыту | Лениногорск муниципаль районының спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура спорт оешмаларында эшләүче югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен тренер-укытучыларга, шулай ук спортчы-инструкторларга һәм спортчыларга ярышларда алган нәтиҗәләре өчен бүләкләү | МКУ «УДМСиТ» | 2026 | Республика бюджеты | 1200,00 |
| 3. | | | Хезмәткәрләргә-Лениногорск муниципаль районы физкультура спорт | | 2026 | Республика бюджеты | 20,00 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | оешмаларының спорт әзерлегенең өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы яшь белгечләренә акчалата түләү | | | | |